... ЯЛТ ИТТЕР КҮҢЕЛЕҢНЕ СЫЗЫ ПАК НУР БЕЛӘН



# Яшь каләмче

**Март ,2024**

Яр Чаллы шәһәре 40 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе МАОУ “СОШ №40

## Бу нинди тавыш дисәм, яз ишек шакый икән...





Яз исе килә...

Тирә- якта ап ак кар булса да,
Яз исе килә...
Нигәдер куңелләрнең,
Язда яшисе килә...

Көннәр озыная барган саен,
Яз исе килә...
Салкын кышны инде без татыдык,
Язда яшисе килә...

Кыштыр кыштыр ак кар асларыннан,
Яз исе килә...
Салкын кышта тугел,ә яшәреп,
Язда яшисе килэ...

*Җил җылы һәм иркә ,*
*Кояш та елмая.*
*Бар дөнья уяна,*
*Бар дөнья уяна.*
*Яз килә! Яз килә!*
*Чәчәкләр уяна.*
*Йөрәккә яз килде, -*
*Бар дөнья куана!*
*Яз килә*

*Идет весна ручьями по дороге,*
*Капелью звонкой с крыш!*
*Повеяло теплом в природе,*
*Весна весна ты чудеса творишь!*
*Разбудишь лес от зимней спячки,*
*Подснежников пробудишь первые цветы!*
*О ,боже! Не это ль счастье?*
*Дождаться солнечные дни!!*
*Лучами солнца ворвешься в душу,*
*Вдохнешь в нее весеннее тепло!*
*Пора времен одна из лучших!*
*Надеждой сердце зацветет!*
*Вид облаков, в лазурь влекущих,*
*Закрался в мысли глубоко!*
*Идет идет весна цветущая,*
*Уж солнца блики высоко.*

***Бүген әле яз башы гына. Төннәрен салкын булса да, көндезен инде кояш балкый. Туган җиребезгә яз килә, яз исе аңкый. Яз − матур, шатлыкларга бай, күңелле вакыт. Түрдән уз, яз!***

***Март аена халык сынамышлары*** ⛅⛅⛅.

*Мартта күк күкрәсә, салкыннар котегез.*
*Күк күкрәмичә генә яшен күрсәгез, җәй салкын булыр.*
*Март яңгырлы булса, гөмбәле җәйгә ишарә.*
*Мартта суык һәм коры булса, икмәк уңар.*
*Мартта боз сөңгеләре озын булса, яз озак килер.*
*Мартта томаннар еш төшсә, яңгырлы җәйгә.*
*Март ахырында карның тиз эрүе һәм суларның тиз китүе дә яңгырлы җәй билгесе*

### Народные приметы.

*Март неверен: то плачет, то смеется.*
*Иногда и март морозами хвалится.*
*В марте мороз скрипуч, да не живуч.*
*Частые туманы в марте предвещают дождливое лето.*
*Если пойдет дождь в марте, вырастет много грибов.*
*Мокрый март — плохой урожай.*
*В марте холодно и сухо — хлеба в достатке будет.*
*Редкие морозы в марте – к урожайному году.*



# Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Жылы кояш нурларына төренеп, йөгерек гөрләвекләре белән йөгереп язның беренче ае — март та килеп җитте. Барыбызга да билгеле, әлеге айның иң матур, иң олы бәйрәме — 8 Март — Халыкара хатын-кызлар көне.

Көннең яктылыгы кояшта, күкнең бар матурлыгы йолдызларында, кешелекнең бөтен гүзәллеге хатын-кызларда.

Кадерле укытучы апаларыбыз, укучы кызларыбыз!Рөхсәт итегез сезне, кешелекнең бизәге булган гүзәл затны, шушы искиткеч матур яз бәйрәме — Халыкара хатын-кызлар көне белән тәбрик итәргә… Шушы гаҗәеп гүзәл бәйрәм көнендә елмаеп баккан кояштай һәрвакыт балкып яшәгез. Күңелегездән шатлык, тәнегездән саулык-сәламәтлек, йортыгыздан иминлек-бәракәт китмәсен! Бәйрәм котлы булсын!

Дорогие наши учителя, девочки нашей школы! Поздравляем Вас с прекрасным праздником 8 Марта! Пусть радует весна цветами, теплом, солнечными лучами, светлым небом над головой, нежностью, любовью и ласковыми улыбками. Пусть Ваше настроение всегда будет цветущим и радостным!

*Бәйрәмнең тарихы 1857 нче елдан башлана. Ул вакытта Нью-Йорк тегүчеләре кечкенә хезмәт хакына канәгатьсезлек белдергән. Нәкъ 8 нче март көнне шәһәрдә массакүләм демонстрациягә чыгалар.*

*Әлеге көнне рәсми төстә бәйрәм итүгә исә Германия революционеры Клара Цеткин сәбәпче.*

***Россиядә 1965 нче елдан 8 нче март рәсми төстә ял көне.***

Урамда яз җилләре исә, яз исе сизелә. Яз битләребезгә дә, хисләребезгә дә үзенең җылысын өрә. Яз үзенең сихри көчләре белән кешеләр күңеленә үк үтеп керә: җан, рухка ниндидер көтелмәгән куаныч иңәр төсле, бәхет-шатлыкка юл ачылыр сыман… Яз ул өметләр һәм аңлаешсыз ниләрдер көтү вакыты, омтылулар, ашкынулар вакыты… Язлар матур, дибез. Бәлки яз хатын-кызлар бәйрәме белән башланганга шулай матурдыр? Ә бәлки хатын-кызлар бәйрәмен үткәрү өчен нәкъ менә шундый матур яз көнен сайлау кирәктер?



8 нче март халыкара-хатын кызлар бәйрәмен безнең мәктәп укучылары да шатланып каршы алдылар.Мәктәпне матур итеп бизәделәр. Матур фотозона ясадылар.Теләгән кеше фотосурәткә төште. Иртәдән үк мәктәптә бәйрәм рухы, җыр-музыка яңгырап торды. Мәктәпнең активистлары яраткан укытучыларын эшкә бүләкләр белән каршы алдылар, аларга котлауларын тапшырдылар.



Ә инде дәресләр беткәч, бик күңелле бәйрәм концерты булды. Монда инде укучылар да, укытучылар да чыгыш ясадылар.

Кем дөньяга кеше бүләк итә?
Ә кешегә якты дөньяны?
Тойгылары кояш кебек кайнар,
Эретерлек гранит кыяны?
Кем куллары өйне, җирне ямьли?
Изгелеге үлчәү тапкысыз.
Ул әлбәттә яшәү чыганагы,
Тормыш яме ул - Хатын-кыз!





**Бәйрәм концертыннан**

# Бик шәп булды бу кичә!




*«Татар кызы - 2024"*

*Быел беренче тапкыр мәктәбебездә 8 нче март -Халыкара хатын-кызлар бәйрәме уңаеннан "Татар кызы-2024" бәйгесе үтте.*

*Чарада берсеннән -берсе уңган, берсеннән-берсе матур , тәрбияле башлангыч сыйныфта укучы кызлар катнашты. Алар тамашачыларга җыр-бию , сәнгатьле итеп шигырь сөйләү буенча иҗат-сәләтләрен күрсәттеләр, сәдәф тагу, борчактан "Әни"сүзен тезү кебек бәйгеләрдә көч сынаштылар. Кызларыбызның һәрберсе татар халык киемен киеп, матур итеп туган, татар телебездә чыгыш ясаулары барыбызны да сокландырды, шатландырды.*




*Нәтиҗәдә, һәр катнашучы гүзәл кызыбыз "Иң уңган", "Иң җитез", "Иң оста биюче", "Иң тыйнак", "Иң оста җырлаучы" һ.б. номинацияләрдә җиңү яуладылар. Аларга грамоталар һәм бүләкләр тапшырылды.*

*Залны тутырып утырган тамашачыга - әниләргә, укытучыларга бәйрәм бик ошады. Афәрин, кызлар, булдырдыгыз! Киләчәктә дә уңышларга ирешегез. Милләтебезнең йөзек кашлары булуыгызны телибез!*



*Кичәне оештыручы укытучылар Таҗиева Рузалия Равгатовнага, Гафиятуллина Нәфисә Ризатдиновнага шундый кичә оештырганнары өчен зур рәхмәт.*



***Әй калфагым, калфагым,***
***Калфаклар кияр чагым.***
***Күңелемә ямь бирүче***
***Нур булды шул калфагым.***

Калфагымның матурлыгын,
Һәммәсе дә күрсеннәр.
Энҗе калфак кигән кыз ул-
Татар кызы дисеннәр.









**"Әни",-диеп язып куйдым**
**Яңа яуган ак карга.**
**Таптамагыз, һич ярамый,**
**"Әни" сүзен таптарга.**





**Россия Федерациясендә сигезенче тапкыр президент сайлаулары 2024 елның 15, 16 һәм 17 мартында узды.**

**Соңгы нәтиҗәләр буенча Россиядә ил халкының** 73 **проценты үз тавышын биргән. Бу – президент сайлаулардагы иң зур күрсәткеч.**
**Россиякүләм үткәрелгән экзит-пул нәтиҗәләре буенча**
**Владимир Путин 87 процент тавыш җыйды.**



# Кышны озатабыз....Табигатькә,тормышыбызга яз килә..

## Масленица,Нәүрүз бәйрәм

**В начале марта россияне празднуют Масленицу, а 21 марта отметили Науруз - байрам.**




В старину считалась масленица праздником поминовения усопших. Так что сжигание масленицы — это ее похороны, а блины — это поминальное угощение. Со временем праздник значительно трансформировался, но осталась традиция печь блины - круглые, желтые и горячие, как солнце.

В последний день масленичной недели происходил ритуал проводов Масленицы, который в разных губерниях России заключался как в сожжении чучела Масленицы, так и в его похоронах. Сожжение чучела было традиционно для северных, центральных и поволжских губерний. В костёр с горящим чучелом бросали традиционную поминальную пищу (блины, яйца, лепёшки).

Православный праздник «Масленица» в 2024 году праздновали с 11 по 17 марта. Наша школа не стала исключением.

Торжественное открытие праздника состоялось 17 марта 2024 года в 10:00.

По традициям, на Масленице кормили вкусными блинами и поили горячим чаем. Также присутствовало пугало, которое должно было привлечь долгожданную весну и проводить знойную зиму.

Тем самым, школа №40 города Набережные Челны отметила Масленицу и встретила весну с теплыми объятьями.

**Пеструхина Екатерина 10** А класс.








## Нәүрүз мөбарәкбад!




Навруз отмечался в день весеннего равноденствия 21-22 марта. В этот день встречали весну.

В этот день люди веселились от души, радовались приходу весны, готовили угощения, ходили в гости, забывали друг другу обиды, просили прощения, желали хозяевам в новом году здоровья, долголетия и богатый урожай.

Нәүрүз сүзе яңа көн дигәнне аңлата. Бу көнне өйдән-өйгә кереп, теләк теләп ,бүләк җыеп йөргәннәр.Йорт хуҗаларына яңа елда саулык-иминлек, кырларга бай уңыш,озын гомер теләгәннәр.Нәүрүз ул - игелек,дуслык бәйрәме. Бу гузәл, язгы матур бәйрәм көнендә кешеләр бер-берсенә кунакка йөриләр, бер берләренә булган үпкәләрен оныталар, бер –берсен гафу итәләр. Ул бәйрәмдә яз кызы гүзәл Нәүрүзбикә белән Кыш бабай көч сынашалар. Нәүрүзбикә җинеп чыга.

Нәүрүз бәйрәме котлы булсын,
Эче тулы нур булсын !
Нәүрәз көен кем көйләсә,
Ул дәртле һәм бай булсын !
Нәүрүз ,Нәүрүз, зур рәхмәт
Телибез изге, теләк.
Бәйрәм мөбәрәк булсын!





**Газетаның баш редакторы Таҗиева Р.Р.**